ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авылы җирлегенең Емелькино авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

2019 елның 28 ноябре № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Емелькино авылы җирлеге Емелькино авылында гражданнар җыены нигезендә

Карар:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Кәкре Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, (I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлар) 300 сум күләмендә үзсалым кертергә

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

**Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Емелькино авылы юлларын агымдагы төзекләндерү (вак таш, ЩПС сатып алу, вак таш салу, грейдлау, торбалар алу);
- **Емелькино авылындагы күперне ремонтлау (товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу)**

**Күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Емелькино авылы чикләрендә урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу?
- **Емелькино авылы буасын ремонтлау (товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу)**

3. Әлеге карарны Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: htt://pravo.tatarstan.ru

Емелькино авылы җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы Н.И.Михайлова